**Сугыш афәте**

# Төрек корбаннары эзеннән

Казан ханлыгы егылгач, татарлар дәүләтләрен һәм үз бәйсезлеген дә югалталар. Кыю һәм батыр халык булганга, аларны еш булган сугышларда һәрвакыт алгы сафларга куялар. Кызганыч ки, Россия дәүләте мөселман илләре белән сугышканда татарларны да катнаштырган. Мәсәлән, Төркия белән 17, 18, 19нчы гасырларда барган сугышларда.

Беренче Бөтендөнья сугышы аеруча дәһшәтле була. Анда 38 дәүләттән 74 миллион гаскәриләр катнаша. Нәтиҗәдә 10 миллион кеше үтерелә, 20 миллион - яралана, имгәнә, гарипләнә. Россия тарафыннан 64 мең төрек гаскәре әсирлеккә алына. Аларны Себергә озатканда көньяктан төньякка таба сузылган тимер юллары буенда корылган шәһәрләргә сибеп урнаштыралар. Ачлык, ялангачлык, хәерчелек хөкем сөргән Рәсәй киңлекләрендә бу мескеннәрнең күбесе мәңгелеккә ятып кала. Төрле эпидемияләр кырган вакытта аларны күмәк каберлекләргә, үләт базларына күмәләр. Шундый каберлек Сызран шәһәренең иске зиратында табылган. Анда төрле кабер калкулыклары белән бергә тирә-ягы казылган бер җир бүлеме бар. Ул биредә күмәк каберлек булу мөмкинлегенә ишарә ясый. Анда куелган кабер ташында гарәп хәрефләре белән язылган бер шактый таушалган язу бар. Язуда «1915» санын һәм "госманлы" дигән сүзне танып укып була. Бу монда төрек кешесе, яисә кешеләре дип фикер йөртү өчен бер этәргеч бирә.

Әлеге хәл белән иң беренче биредә яшәүче һәвәскәр тарихчы Н.И. Подлеснов кызыксынган. Ул мәсьәләне Сызран шәһәренең имам-мөхтәсибе Илгизәр хәзрәт Сәгъдиев инде берничә ел элек күтәреп чыккан иде. Төркия илендәге дәүләт һәм җәмгыять эшлеклеләренә бу хакта хәбәр биргәч, алар үзләренең кызыксынуларын белдерделәр.

Февраль ае башында Самарга Казан шәһәрендә урнашкан консульстводан генераль консул җитәкчелегендә бер төркем кунаклар килде. Аларның максаты - бу хәбәрне тирәнрәк өйрәнү һәм күп нәрсәне ачыклау иде. Очрашуда Самар өлкәсе Диния нәзарәте рәисе Талип хәзрәт Яруллин, тарихчылар, журналистлар катнашты.

Тарихка, бигрәк тә аның сугышлар белән бәйләнгән өлешенә кагылу, бик зур саклык һәм уйлап эшләүне таләп итә.

Менә бу табыш та - тарихыбызның тагын бер тирән яралы өлеше. Ватаныбыз тарихы бай, әчтәлекле, гыйбрәтле булса да, ул бик катлаулы. Аның кайсы гына чорын, тармагын актарып карасаң да, үсешләр, зур казанышлар артында тирән фаҗигалар, зур югалтулар күрәсең.

Бу сәфәрдәге очрашудан соң, башка төрле уйлар килә. Менә бу хәрәкәт ниндидер шәхси амбицияләр, омтылышлар гына булып калмасын иде.

**Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.**

# Изгелек

Самар Җәмигъ мәчете каршындагы «Нур» мәдрәсәсе бинасында төрле тормыш кирәк-яракларын кабул итү пункты ачылды, һәм биредә актив эшләр башкарыла. Монда халыктан арткан яңа яисә кулланууда булып та, әле сыйфатын артык югалтмаган кием-салып, җиһазлар, төрле тормыш кирәк-яраклары кабул ителә. Аларны мохтаҗлыкта интеккән кешеләр, интернатлар, махсус реабилитация оешмалары шатланып кабул итәләр. Бу турыда «Ислам-Нур» газетасында мәгълүмат басылган иде инде. Шушы хәбәрне ишетеп, бу изге акциягә Челно-Вершины районындагы Заиткино авылы кешеләре дә кушылырга карар кабул итеп, төрле-төрле әйберләр җыялар һәм бирегә җибәрәләр. Әйберләр, ризыклар арасында шәкертләр өчен әзерләнгән бәрәңге, суган, кишер, кәбестә, шалкан, чөгендер - барысы да күп итеп җыелган. Бу авылда үзенең фермер хуҗалыгын алып барган Тәлгат Тәхвәтуллинны да телгә аласы килә. Ул үзе җыеп алган уңыштан зәкят бирү рәвешендә бу эшкә үз өлешен кертә. Самар Җәмигъ мәчете хезмәткәре Рәфкат Фәрдиев та бу товарларны Самар шәһәренә үз машинасында алып килә. Ул «Ислам-Нур» газетасына язылучылар санын күбәйтү өчен дә тырышлык күрсәтә. Без аңа зур рәхмәтлебез.

**Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.**

**Толерантность**

# В общении укрепляется дружба, воспитывается взаимоуважение

Прогресс в любом государстве возможен только при наличии взаимоуважения и добрососедства между его народами. Россия - страна многонациональная. Поэтому этот вопрос имеет огромное значение. В настоящее время, когда в обществе нарастает безнравственность, вопрос воспитания молодого поколения обретает особую актуальность.

Отрадно то, что сегодня в Самарской области общественные движения различных народов и религиозных конфессий ищут и находят общие точки соприкосновения.

23 февраля в здании МТЛ «Арена» представители 12 религиозных конфессий собрались вместе для участия в соревнованиях по мини-футболу.

Несмотря на то, что это простая игровая встреча молодежных команд, она имеет многостороннее значение.

Во-первых - это чествование праздника Дня защитника Родины.

Во-вторых, это не враждебное противостояние, а дружеская встреча.

Спорт - это мощное средство воспитания тела и духа.

В-третьих, эта встреча еще ценна тем, что она проходит не по принуждению и приказу сверху. Это инициатива самих представителей различных религиозных конфессий, что является уникальным явлением в масштабе всей страны.

В-четвертых, во время беседы вокруг импровизированного «круглого стола» были высказаны новые предложения по поводу организации совместных встреч. Например, как организация общей уборки парков, набережной зоны отдыха реки Волга.

Надо признать, что Региональное Духовное управление мусульман Самарской области все более активно расширяет сферы своей деятельности в работе как с татарскими общественными организациями, так и с организациями других народов, при этом активно участвуя в «круглых столах» и диспутах.

Одним словом, мусульманское управление Самарской области перестает быть только лишь обособленным каноническим структурным подразделением. Все большую активность начинает проявлять молодое поколение. В мечетях все больше встречаются образованные социально-активные молодые люди. Расширяется благотворительная деятельность. Хочется надеяться, что в дальнейшем воспитательная и направляющая воля Всемогущего Аллаха, Его призывы будут услышаны большей частью этнических мусульман.

А подобные встречи с представителями других религиозных конфессий просто необходимы. Мы воочию должны показать, что Ислам - религия мира и добра. А мы, его приверженцы, традиционно воспитаны в духе патриотизма, уважения и почитания достоинства других народов, с которыми вместе проживаем.

Своей воспитанностью, толерантностью мы должны показать, что приверженцы истинного Ислама не являются носителями зла. Мы, как и все народы, хотим мира, добрососедства между нашими народами и процветания нашей общей Родины. А отщепенцы находятся в любом обществе, и в любой религии. Судить по ним и делать умозаключения - это ошибка, которая ведет только к негативу. Хочется верить, что татарские национально-культурные организации смогут объединить свои усилия вокруг центра духовности Самарского региона.

Любое общество сильно своим единством. Только при этом нас ждет успех, удача, а главное - уважение и восхищение других народов.

***Фарид ШИРИЯЗДАНОВ.***

**Мөхәммәд (с.г.в.): «Шигырьдә хикмәт бар»**

# Шигырь күңелне үстерә, җанны тәрбияли, хисләрне баета

Тормыштагы авырлыклардан без ип-исән, таза ирләрнең дә, төшенкелеккә бирелеп, түбән тәгәрәүләрен еш күрәбез. Аллага шөкер, моның белән бергә сабырлык, түземлек, чыдамлык үрнәге алырлык шәхесләребез дә бар: татар дөньясында киң танылган, Самарның «Мәшһүр татары» исемен йөрткән, Тукай премиясенә лаек булган бөек шагыйребез Гакыйл абый Сәгыйровны мисал өчен алыйк.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә: "Аллаһы Тәгалә иң яраткан кешесенә зур сынаулар бирә", - дигән. Әйе, ул Гакыйл абыйга сынау газапларының иң көчлесен биргән. Шул ук вакытта матур сыйфатларын, киң кырлы сәләтен дә мул итеп биргән. Аяк-кулын, гәүдәсен кыймылдата алмаса да, ул искиткеч матур рәсемнәр ясап, җаннарны тетрәндерерлек шигырьләр язып, безгә үзенең бай мирасын калдырды. Аның яшәү рәвеше, уйлары, иҗаты - барысы да үрнәк һәм тәрбия рәвеше.

Самар шәһәренең "Яктылык" мәктәбендә шагыйрьнең туган көненә багышланган әдәби-музыкаль кичә узды. Анда укытучылар һәм укучылар актив катнаштылар. "Яктылык" мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нурзидә Фәйзуллина һәр елны даһи шагыйребез, рәссамыбыз Гакыйл ага Сәгыйровның туган көненә багышлап, матур бәйрәм оештыра. Әлбәттә, бу кыска вакытта эшләнә торган эш түгел. Нургизә ханым ел әйләнәсендә Гакыйл Сәгыйров, Габдулла Тукай, Муса Җәлил һәм башка шагыйрьләребезнең, язучыларның әсәрләре нигезендә үз укучыларында милләтебезгә, телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли. Менә быел да бу чара оешкан төстә, Гакыйл Сәгыйровның иҗаты бөеклегенә лаеклы булып узды. Самар өлкәсенең татар милли-мәдәни мохтарияте мөдире Равил Галимов укучыларга бүләкләр тапшырды.

Бу бәйрәмдә озак еллар "Ялкынлы яшьлек" ансамблен җитәкләүче, гомере буена татар сәнгатен, мәдәниятын кайгыртып яшәүче Самар өлкәсенең "Туган тел" исемле татар җәмгыяте вице-президенты Илгиз ага Колючев та катнашты. Шигырь сөюче, нечкә хисләргә бай шәхес буларак, ул Гакыйл Сәгыйров иҗаты хакында сокланып сөйләде.

Шагыйрьнең иҗаты - ул безнең өчен тормыш дәресе. Күп кенә катлаулы мәсьәләләрне ул кыска шигырь юлларында гади генә, ләкин тирән сеңдереп аңлата.

Бөек шагыйрь якташыбызны искә алып, аның иҗатына сокланып, без үз хисләребезне баетабыз, күңелебезне тазалыйбыз. Ә иң әһәмиятлесе - бу бәйрәм балалар өчен көчле тәрбия чарасы. Шагыйрь телебез гүзәллеген, тормыш матурлыгын, кыйммәтле киңәшләрен - барысын да кыска шигырь юлларына сыйдыра алган.

"Яктылык" мәктәбе укытучысы Госман кызы Асия Сәйфетдинова балаларны да, олыларны да көчле хисләр белән язылган шигырьләрне чын күңел биреп, йөрәгебез аша үткәреп, тулысынча аңлап кабул итәргә чакырды. Бу чара матур җырлар белән бизәлеп, барыбызда да тирән хисләр уятты. Пәйгамбәребез хәдисләрендә: «Шигырьдә хикмәт бар», - дип язылган. Шигырь яраткан, аны аңлап кабул иткән кеше беркайчанда алдакчы да, хыянәтче дә, җинаятьче дә була алмый. Шигырь юллары - күңелне тәрбияләүче, хисләрне баетучы серле сүзләр тезмәсе.

Шагыйрь якташыбыз Гакыйл Сәгыйровка ихтирам, аның шигырьләренә мәхәббәт уяту - ул бик көчле тәрбия чарасы. Балага кирәкле мәгълүматларны җырлар белән бизәп, моңнарга төреп җиткерсәң, моның нәтиҗәсе дә файдалы була.

**Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.**